
# Кисәкчәләр иленә



**“Игелекле эшнең иртәсе-киче юк”**

# Сәяхәт картасы



# “Маймыллар утравы”

Без кызыклы маймыллар,
Уйныйбыз, сикерәбез.
Әйдәгез бергәләп,
Туп белән йөгерәбез.



# У е н

- “Кисәкчәләрне әйт”

Уен тәртибе:

Кисәкчә әйт һәм тупны иптәшеңә ыргыт

# “Су анасы култыгы”

Һай!
Тарагымны,
алтын
тарагымны
югалттым бит...



| | |
|---|---|
| Өчпочмак | да |
| Яңгыр | та |
| Өстәл | тә |
| Сәгать | дә |
| Озын | кына |
| Нәни | кенә |
| Сикереп | гына |

* Саңгырау тартыкларга беткән сүзләр янында саңгырау тартык аваздан башланган кисәкчәләр килә.



# Тарагым табылды, рәхмәт!



# “Су кызлары кыясы”

**Без су кызлары –**

**русалкалар,**

**Диңгез серен беләбез.**

**Ә кисәкчәләр буенча ,**

**Сезнең ярдәмгә**

**мохтаҗ без.**



# Сигезаяклар чоңгылы


Минем кайгым бик зурдан,
Улым качкан өемнән.
Булышыгзчы миңа,
Ярдәм көтәм мин сездән...



* Кисәкчәләр аерым язылалар
* Калын әйтелешле сүзләр янында калын, нечкә әйтелешле сүз янында нечкә кушымча килә.

* Кисәкчәләр бәйләнеп килгән сүзләргә кемдә? нәрсәдә? кайда? сораулары куеп булмый. “Безнең авыл артындагы урманда ылыслы агачлар да үсә” җөмләсе мисалында аңлатырга.

# РӘХМӘТ СЕЗГӘ!!!



# АЛТЫН БАЛЫК ПАТШАЛЫГЫ





# Шигырь иҗат ит!

Бирелгән рифмаларны кулланып, дүрт юллы шигырь яз:

______________________________гына

______________________________кына

______________________________сагына

______________________________кагына.

# Килеп чыккан җөмләләрне әйт:

Өйрәнгән кисәкчәләрне төрле сүзләр янына куеп кара. Килеп чыккан җөмләләрне әйт:

Балалар иртәгә урманга баралар.

# **Кисәкчә куй**

Сызыклар урынына тиешле кисәкчәне куй:

Урманда нарат ___, чыршы ___ бар.

# Кисәкчәләрне әйт

Җәя эчендәге кисәкчәнең тиешлесен әйт:

Ары (да,дә) килеп биисең,

Бире (да, дә) килеп биисең.

Яңа (гына, генә) тәпи йөреп

Киткәнеңне белмисең.

# Кисәкчәләрне тап!

*Чыршы шигырендәге кисәкчәләрне әйт.*

Җәй дә яшел, көз дә яшел,

Кыш та яшел шулай ук.

Энәләре күп булса да,

Җебе анын бер дә юк.

# Кисәкчә кертеп җөмлә төзе



Кисәкчәләр җөмләдә нинди роль уйный?

# Өй эше:

Дәреслек :

148 нче бит,

257 нче күнегү